КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 сентябрь г.Казань № 969

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 ел, 20 сентябрь, 890 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 ел, 20 сентябрь, 890 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 декабрь, 1300 нче; 2022 ел, 8 апрель, 339 нчы; 2022 ел, 7 июнь, 531 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаручы медицина оешмалары норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларында:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» юлында «1,215101» саннарын «1,218605» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» юлында «0,491909» саннарын «0,491901» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2022 елга донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары башкара торган дәүләт эше күләмнәрендә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» бүлегендә:

«кан донорларыннан компонентларга аертылмаган донорлар каны» юлының 5 графасында «2 152,9» саннарын «2 879,6» саннарына алмаштырырга;

«автоматик аферез ысулы белән компонентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасында «2 668,1» саннарын «4 333,4» саннарына алмаштырырга;

«тромбоцитоферез ысулы белән ком-понентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасында «1 281,0» саннарын «4 374,0» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин